ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г. Казань № 641-107/кс-2023

Зеленодольск муниципаль районының «ЗВКС» акционерлык җәмгыяте өчен агынты суларны чистартуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2021 №494-152/кс-2021 карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2024 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 14.12.2023 №58-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, агынты суларны чистартуга 2024-2026 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемнә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Зеленодольск муниципаль районы «ЗВКС» акционерлык җәмгыяте өчен агынты суларны чистартуга 2022-2026 елларга тарифлар билгеләү турында» 10.12.2021 №494-152/кс-2021 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.11.2022 №599-173/кс-2022 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ЗВКС» АҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023

елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2021 № 494-152/кс-2021 карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2023 № 641-107/кс-2023 карары редакциясендә)

# Су агызуны гамәлгә ашыручы «ЗВКС» АҖ өчен агып җыелган суларны чистартуга 2022-2026 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Агынты суларны чистартуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Зеленодольск муниципаль районы | | |
| 1 | «ЗВКС» АҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелә) | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 9,73 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 9,97 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 10,47* |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 9,66 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 9,66 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 9,60 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 9,60 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 9,60 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 10,44 |

<*> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.11.2022 №599-173/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге